| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» август 2022г. с. Тюлячи № 155

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы (шәһәр округы) җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Мәгариф төрен колачлаган 15-21 яшьтәге халык өлеше» ярдәмче күрсәткечен хисап чорына исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлегe регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 21 июлендәге 9760/22 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указлары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Мәгариф төрен колачлаган 15-21 яшьтәге халык өлеше» ярдәмче күрсәткечен хисап чорына исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлеге регламентын расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлеев

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«26» 08 2022 № 155
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы (шәһәр округы) җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Мәгариф төрен колачлаган 15-21 яшьтәге халык өлеше» ярдәмче күрсәткечен хисап чорына исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлеге регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Регламентны җайга салу предметы

Әлеге Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Мәгариф төрен колачлаган 15-21 яшьтәге халык өлеше» ярдәмче күрсәткечен хисап чорына исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлеге регламенты Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указлары, «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 елның 31 декабрендәге 920 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы «Контроль» модуленең эшләве тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 18 апрелендәге 361 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнелгән һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы (шәһәр округы) җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Мәгариф төрен колачлаган 15-21 яшьтәге халык өлеше» ярдәмче күрсәткечен (алга таба - декомпозицияләнгән күрсәткеч) хисап чорына исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау тәртибен билгели:

төп гомуми белем бирү программалары буенча 15-21 яшьтәге укучылар саны;

урта һөнәри белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча 15-21 яшьлек балалар саны;

югары белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча 15-21 яшьтәге укучылар саны.

Теләче муниципаль районында декомпозицияләнгән күрсәткечләрне җыю һәм мониторинглау өчен «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ (алга таба - мәгариф бүлеге) җаваплы.

1.2. Белешмә мәгълүматы

Әлеге регламентның максатлары өчен муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Мәгариф төрен колачлаган 15-21 яшьтәге халык өлеше» ярдәмче күрсәткечен хисап чорына исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау методикасында билгеләнгән терминнар кулланыла,алар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары белән кертелгән.

## 2. Исәп-хисап стандарты, җыю тәртибе һәм белешмәләр бирү

Декомпозияләнгән ярдәмче күрсәткечне исәпләп чыгару өчен түбәндәге мәгълүматлар кулланыла:

төп гомуми белем бирү программалары буенча 15-21 яшьтәге укучылар саны;

урта һөнәри белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча 15-21 яшьлек балалар саны;

югары белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча 15-21 яшьтәге укучылар саны.

Мәгариф бүлегенең җаваплы хезмәткәре төп гомуми белем бирү программалары буенча хезмәт күрсәтүче оешмалардан, урта һөнәри белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча, югары белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча хисап чорында югарыдагы күрсәткечләрне җыюны гамәлгә ашыра.

Муниципаль район буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасында рәсми хат белән бирелә.

## 3. Мәгълүматларның составы, срогы һәм бирү рәвеше

3.1. Төп гомуми белем бирү программалары буенча хезмәт күрсәтүче оешмалар тарафыннан әлеге хезмәтләрне күрсәтү формасы 1 Таблицада күрсәтелгән.

1 таблица

Төп гомуми белем бирү программалары буенча 15-21 яшьлек укучылар саны

| № т/б | Төп гомуми белем бирү программалары буенча хезмәтләр күрсәтүче оешма аталышы | Үлчәү берәмлеге (кеше) | Хисап аеннан соң килә торган айның 1 числосына кадәр квартал саен мәгълүмат бирү срогы | Төп гомуми белем бирү программалары буенча 15-21 яшьлек укучылар саны |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

3.2. Урта һөнәри белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмалар тарафыннан әлеге мәгълүматларны бирү рәвеше 2 Таблицада бирелгән.

2 таблица

Урта һөнәри белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча 15-21 яшьләрдәге укучылар саны

| № т/б | Урта һөнәри белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча хезмәтләр күрсәтүче оешма исеме | Үлчәү берәмлеге (кеше) | Хисап аеннан соң килә торган айның 1 числосына кадәр квартал саен мәгълүмат бирү срогы | Урта һөнәри белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча 15-21 яшьләрдәге укучылар саны |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

3.3. Югары белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча хезмәт күрсәтүче оешмалар тарафыннан әлеге мәгълүматларны бирү рәвеше 3 Таблицада күрсәтелгән.

3 таблица

**Югары белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча 15-21 яшьләрдәге укучылар саны**

| № т/б | Югары белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча хезмәтләр күрсәтүче оешма исеме | Үлчәү берәмлеге (кеше) | Хисап аеннан соң килә торган айның 1 числосына кадәр квартал саен мәгълүмат бирү срогы | Югары белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча 15-21 яшьләрдәге укучылар саны |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |